**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧЫБЫКЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**№119** **«24» сентябрь 2018 ел**

**Чыбыклы авыл жирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча жирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл жирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Чыбыклы авыл жирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча жирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2019 елда тавыш бирү көненә 18 яше тулган яшәү урыны Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл жирлеге чикләрендә урнашкан авыл жирлегендә яшәүче һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, елга бер мәртәбә 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасы түләүне кертү, жыелган акчаларны жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Чыбыклы авылы: урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алмаштыру; гидрант урнаштыру (2 д.); игъланнар тактасы урнаштыру (3 д.);
- Суык-Чишмә авылы: урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алмаштыру; гидрант урнаштыру (1 д.): зиратны төзекләндерү;
- Унбия авылы: урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алмаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта, Чыбыклы авыл жирлеге башкарма комитетына референдум белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча жибәрүне рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ ЮК».

3. Карарны жирлекнең мәгълүмат стендларында һәм авыл жирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка житкерергә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Авыл җирлеге**
**Башлыгы** **И.Н.Гадершин**